ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АКБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР №7

Акбаш ав. 28.01.2022 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлегенең 2021 елның2 июлендәге 9 санлы карары белән кабул ителгән «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү, чисталыкны һәм тәртипне саклау кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2021 елның 6 декабрендәге «Ветеринария турында»гы Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертү хакында»гы 397-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы, Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 июлендәге 10 санлы карары белән кабул ителгән Ютазы муниципаль районының «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Советының норматив хокукый актларын Россия Федерациясе законнары нигезендә китерү максатында Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Советының 2021 елның 2 июлендәге “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү, чисталык һәм тәртип саклау кагыйдәләренә”9 карары белән кабул ителгән тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 17.1 пунктының 24 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«а) хайваннар авыруларын кисәтүне һәм хайваннар продукциясенә ветеринария-санитария мөнәсәбәтендә куркынычсызлыкны тәэмин итүче хуҗалык һәм ветеринария чараларын гамәлгә ашырырга, әйләнә-тирә мохитнең терлекчелек калдыклары белән пычрануына юл куймаска, шулай ук ел саен яңадан теркәлү чорында мәҗбүри дәвалау-профилактика чараларын үткәрергә;».

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Акбаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы

сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында «рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгәннән бирле үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Советының социаль мәсьәләләр буенча комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Акбаш авыл җирлеге башлыгы Л.Р.Синагатуллина